ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55$^2$ статьясына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 июнендә
кабул ителде

## 1 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55$^2$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3), аңа түбәндәге эчтәлекле 4$^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

“4$^1$. Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләме агымдагы финанс елында һәм (яисә) чираттагы финанс елында:

Татарстан Республикасы Юллар фондын формалаштырганда исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фактта кергән һәм фаразланган күләме арасындагы уңай аермага арттырылырга тиеш;

Татарстан Республикасы Юллар фондын формалаштырганда исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фактта кергән һәм фаразланган күләме арасындагы тискәре аермага киметелергә мөмкин.”.

## 2 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 17 статьясындагы 2 пунктының, 53$^1$ статьясындагы 2 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11

(I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3) гамәлдә булуын 2017 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 29 июне
№ 49-ТРЗ